| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1075

Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен биргүгә бәйле булган аерым мәсьәләләр турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115, $115^2$ һәм $115^3$ нче статьялары һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 37 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен биргәндә принципалның финанс хәлен анализлауны, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен биргәннән соң принципалның финанс хәлен мониторинглауны гамәлгә ашыру тәртибен;

Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен биргәндә тәэмин итүнең җитәрлеген, ышанычлыгын һәм ликвидлылыгын тикшерүне, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен биргәннән соң бирелгән тәэмин итүнең җитәрлеген, ышанычлыгын һәм ликвидлылыгын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен;

Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе буенча принципалга карата гарантның регресслы таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләре үтәлешен тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе гамәлдә булган вакыт эчендә принципалга карата гарантның регресслы таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләре үтәлеше буенча бирелгән тәэмин итүнең җитәрлек булмавы ачыкланганда (шул исәптән принципалның, принципалга карата гарантның регресслы таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләре үтәлешен тәэмин итү өчен банк гарантиясен биргән юридик затның финанс хәле шактый начарланган яки җаваплылыкны үз өстенә алган, залог предметының базар кыйммәте арзанайган очракта), принципал тарафыннан 90 көн эчендә тәэмин итүнең составын һәм гомуми күләмен (суммасын) Россия Федерациясе Бюджет кодексы,

Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләргә туры китерү максатларында тәэмин итүне (тулысынча яки өлешчә) алыштыру гамәлгә ашырыла яки өстәмә тәэмин итү (җитмәгән суммага) бирелә.

3. 100 процент акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасына караган хуҗалык җәмгыяте яки мөлкәте Татарстан Республикасы милкендә булган һәм йөкләмәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе бирелгән дәүләт унитар предприятиесе булып торган принципалны тулысынча яки өлешчә хосусыйлаштырган очракта, принципал хосусыйлаштыру тәмамланган көннән 90 көн эчендә гарантның регрессы таләбен канәгатьләндерү буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының $115^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе граждан законнары таләпләренә туры килә торган һәм гарантияне тулы күләмдә яки аның нинди дә булса өлешен үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән үз йөкләмәләре үтәлешен тәэмин итүне башкара.

4. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин